**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

# КАРАР

«31» октябрь 2025 ел № 5

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 29, 30, 31 октябрендә узган: «2026 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Кәкре Атау торак пункты территориясендә һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган салымны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.
2) урамнарны яктырту җайланмасы.
3) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.
4) торак пункт территориясен төзекләндерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 276 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 203 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 184 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 19 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Кәкре Атау торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. 2026 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Кәкре Атау торак пункты территориясендә һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган салымны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

урамнарны яктырту җайланмасы.

су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

торак пункт территориясен төзекләндерү мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кәкре Атау торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Н.В.Авдеева

Гәйтән авыл җирлеге башлыгы Н.В.Авдеева